ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 21 » марта 2022 ел** **№ 56**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру буенча муниципаль штаб (проект офисы) төзү турында**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру максатыннан, Арча муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру буенча муниципаль штаб (проект офисы) төзергә.

2.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру буенча муниципаль штаб (проект офисы) составын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру буенча муниципаль штаб (проект офисы) турында нигезләмәне әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Район башлыгы И.Г.Нуриев

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башлыгының
21 март 2022ел, №56
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру буенча муниципаль штаб (проект офисы)**
**СОСТАВЫ**

Штаб җитәкчесе:

Галимуллин И.Ә.- Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары(килешү буенча);

Штаб әгъзалары:

1. Мөхәмәтова Алсу Фирдәүсовна-Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары;

2.Вафина Э.Ш. - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча);

3.Шаһиәхмәтов Р.Д. -Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча);

4. Әюпов И.И. - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ башлыгы;

5. Мөхәмәдияров Р.Д.- Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ башлыгы;

6. Кадыйров Илнар Әнвәрович – Арча муниципаль районы Башкарма комитеты инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча);

7.Габделгазизов И.Н. - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы (килешү буенча);

8.Галимова С.П. - «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУ җитәкчесе (килешү буенча);

шулай ук авыл җирлекләре муниципаль берәмлекләре башлыгы килешүе буенча (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башлыгының
21 март 2022 ел, № 56
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру буенча муниципаль штаб (проект офисы) турында нигезләмә (алга таба - Нигезләмә)**

## I. Гомуми нигезләмәләр

Муниципаль штаб (проект офисы) (алга таба-штаб)-муниципаль берәмлекләрдә тормышка ашырыла торган проектларны, өстенлекле проектларны (программаларны), федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыруны мониторинглый һәм бәя бирә торган киңәшмә орган.

Штабны (проект офисын) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгы билгеләп куйган җитәкче җитәкли.

Штаб (проект офисы) үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль норматив хокукый актларга таяна.

## II. Штабның (проект офисының) бурычлары һәм функцияләре

Штабның (проект офисының) төп бурычлары һәм функцияләре түбәндәгеләр:

- өстенлекле проектларны (программаларны) гамәлгә ашыру буенча идарәчел карарлар кабул итү;
- өстенлекле проектларта (программаларда) катнашучыларның эшчәнлеген координацияләү;
- бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм проект эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә норматив хокукый җайга салуны тәэмин итү;
- муниципаль район территориясендә федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген мониторинглау һәм анализлау;
- үткәрелгән мониторинг нигезендә аларны үтәүдә өстенлекле проект (программа) чараларын актуальләштерү буенча тәкъдимнәр кертү;
- муниципаль район территориясендә федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру турында мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләү;
- өстенлекле проектларны (программаларны) актуальләштергәндә муниципаль районның җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы

- өстенлекле проектларны (программаларны) актуальләштергәндә муниципаль районның җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

- үз утырышларында кергән проект (программа) тәкъдимнәрен карау;

- өстенлекле проектлар (программалар) паспорты проектын хуплау;

- өстенлекле проектларның (программаларның) җыелма планын раслау, кирәк булганда, аңа үзгәрешләр кертү;

- өстенлекле проектларны (программаларны) гамәлгә ашыруның барышы турында мәгълүматны карау һәм муниципаль район хакимиятенең структур бүлечәләре һем өстенлекле проектта (программада) катнашучыларның тиешле эшченлеге өлкесен координацияләү;

- өстенлекле проектларның (программалар) җыелма планының контроль нокталарын узу турында карарлар кабул итү: контроль нокталарга ирешү срокларын күчерү, өстенлекле проектларның (программаларның) контроль нокталарын тәмамлау өчен өстәмә ресурслар, катнашучылар җәлеп итү мөмкинлеген карау;

- өстенлекле проектларны (программаларны) гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча штаб (проект офисы) әгъзаларын тыңлау;

- муниципаль районның өстенлекле проектны (программаларны) гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль район составындагы җирле үзидарә органнары һәм җирлекләр, оешмалар һәм эшкуарлык бергәлеге вәкилләрен тыңлау;

- өстенлекле проектларны (программаларны) гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар проектлары буенча карарлар кабул итү;

- өстенлекле проектларны (программаларны) гамәлгә ашыру турында хисапларны хуплау;

- өстенлекле проектлар (программалар) җитәкчеләренең эшчәнлек максатларын һәм күрсәткечләрен билгеләү, аларның эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү;

- хезмәт, финанс һәм матди-техник ресурсларны планлаштыру;

- планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итү;

- нәтиҗәләргә ирешү срокларын үтәү яисә кыскарту;

- ресурслардан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;

- муниципаль районда проект эшчәнлеге белән идарә итүне оештыру-методик озата баруны һәм идарә итүне тәэмин итү;

- муниципаль районда проект эшчәнлеген оештыруга ярдәм итү;

- проект инициативаларын карау һәм проект буларак чаралар комплексын гамәлгә ашыру мөмкинлеген билгеләү;

- проектларны (проектлар портфельләрен) муниципаль реестрга кертүне тәэмин итү, паспортларны, проектларны (проектлар портфельләрен) ябу һәм кабул итү турындагы актларны раслау;

- проектларны (проектлар портфельләрен) гамәлгә ашыруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

-барлык типтагы проектларны мониторинглауны тәэмин итү;

- проект эшчәнлеге белән идарә итү системасын үстерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

- проект эшчәнлеге белән идарә итү өлкәсендә норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшереп тору;

- муниципаль районда структур бүлекчәләрнең проект офисларын төзү турында тәкъдимнәр әзерләү;

- муниципаль районда проект белән идарә итүгә өйрәтүне координацияләү.

## III. Штабның (проект офисының) хокуклары һәм вәкаләтләре

Штаб (проект офисы) түбәндәге хокукларга ия:

- муниципаль районның җирле үзидарә органнарыннан, муниципаль район башкарма комитеты бүлекчәләреннән, предприятие һәм оешмалардан штабка (проект офисына) йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле белешмәләр һәм материаллар соратып алырга;

- муниципаль районның планлаштырылган һәм проект эшчәнлегенә билгеләнгән тәртиптә үзгәрешләр кертергә;

- катнашучылар тарафыннан проектларны башкару өчен мәҗбүри булган норматив методик документлар әзерләргә;

- штаб (проект офисы) компетенциясендәге мәсьәләләр карала торган киңәшмәләрдә һәм башка чараларда катнашырга.

## IV. Штаб (проект офисы) эшен оештыру һәм аның составы

Штаб (проект офисы) эшчәнлегенең төп формасы булып штаб (проект офисы) утырышы тора.

Штаб (проект офисы) структурасын һәм санын Татарстан Республикасы муниципаль районы башлыгы эшчәнлек шартларыннан һәм үзенчәлекләреннән чыгып раслый.

Штаб (проект офисы) составы штаб (проект офисы) функцияләренә бәйле рәвештә формалаша.

Штаб (проект офисы) җитәкчесе:

- штаб (проект офисы) эшен оештыра һәм контрольдә тота;

- билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгына штаб (проект офисы) эшчәнлегендә ирешелгән нәтиҗәләр турында хәбәр итә;

- үз компетенциясе чикләрендә штаб (проект офисы) эшчәнлегенә кагылышлы документларны имзалый;

- проектны гамәлгә ашыруда катнашучы барлык катнашучылар белән штабның (проект офисының) нәтиҗәле хезмәттәшлеген оештыра;

- штаб (проект офисы) утырышларын әзерләүне тәэмин итә;

- штаб (проект офисы) карарларының үтәлешен тикшереп тора;

- проект эшчәнлеген оештыруны регламентлый торган норматив хокукый актлар проектларын килештерә;

- ведомство буйсынуындагы оешмаларда проект эшчәнлеген оештыруны координацияләүне һәм мониторинглауны тәэмин итә;

- нәтиҗәлелек күрсәткечләрен мониторинглау инструментын гамәлгә кертүне тәэмин итә;

- проектлар белән идарә итү һәм документлар әйләнеше процедураларын үстерүне һәм хуплауны оештыра;

- проект офислары һәм проект эшчәнлегенең башка катнашучылары һәм аны гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча эшләүче затлар белән үзара хезмәттәшлекне тәэмин итә;

- коммуникацияләр белән идарә итү процессын җайга сала, проектларны гамәлгә ашыру проблемаларын бетерүгә яисә киметүгә юнәлдерелгән чараларда катнаша;

- проект эшчәнлеген популярлаштыруны һәм проект культурасын үстерүне тәэмин итә;

- проектларны администрацияләү эшен җайга сала;

-проект эшчәнлегендә катнашучы хезмәткәрләрне кызыксындыру системасын булдыруны һәм үстерүне җайга сала;

- проект эшчәнлеге өлкәсендә хезмәткәрләрнең һөнәри компетентлыгын үстерү һәм тәҗрибә туплау эшчәнлеген координацияли.

Штаб (проект офисы) әгъзалары штаб (проект офисы) бурычларын һәм функцияләрен алар арасында штаб (проект офисы) җитәкчесе тарафыннан бүленгән бурычларга туры китереп башкаралар.

<u>Проектларны гамәлгә ашыруны озата бару юнәлеше буенча штаб (проект офисы) әгъзалары бурычлары:</u>

- проектлар белән идарә итү мәсьәләләре буенча проект эшчәнлегендә катнашучыларга консультация бирә;

- проект буенча документларга мәгълүмати белешмәләр, аналитик материаллар һәм эксперт бәяләмәләре әзерли;

- проект эшчәнлеге белән идарә итүне гамәлгә кертүнең яңа процессларын сынап карауда катнаша;

- проект эшчәнлеге реестрларын тулыландыра һәм аны актуаль хәлдә тота;

- проектлар буенча документлар архивын алып баруны тәэмин итә һәм актуаль хәлдә тота.

<u>Проектларны гамәлгә ашыруны мониторинглау юнәлеше буенча штаб (проект офисы) әгъзалары бурычлары:</u>

- муниципаль район территориясендә республика программаларын һәм федераль программаларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелегенә мониторинг үткәрә һәм анализ ясый;

- муниципаль район территориясендә республика программаларын һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру турында мәгълүмати-аналитик материаллар әзерли;

- максатлар, күрсәткечләр мониторингын, бурычларны хәл итүне һәм

нәтиҗәләргә, контроль нокталарга һәм проект эшчәнлегенең башка элементларына ирешүне дә кертеп, проектларны гамәлгә ашыру статусын даими нигездә мониторинглауны гамәлгә ашыра;

- проектларны мониторинглау кысаларында аналитик материаллар, презентацияләр һәм хисап әзерли;

- проектларны һәм проект эшчәнлеген гамәлгә ашыру мониторингы инструментларын үстерүдә катнаша;

- мониторинг буенча документлар архивын тулыландыра һәм актуаль хәлдә тота;

- штаб (проект офисы) тарафыннан проектларга карата оештырылган контроль чараларда катнаша.

<u>Проект белән идарә итүгә өйрәтү һәм методологиясе юнәлеше буенча штаб (проект офисы) әгъзалары бурычлары:</u>

- проект белән идарә итүгә өйрәтү һәм методологиясе мәсьәләләре буенча проект эшчәнлегендә катнашучыларга консультация бирә;

- проект белән идарә итү методологиясен эшли, аны гамәлгә кертүне һәм актуальләштерүне тәэмин итә;

- методология буенча документлар архивын тулыландыра һәм актуаль хәлдә тота;

- проект идарәсе өлкәсендә иң яхшы тәҗрибәләрне туплауны һәм гамәлгә кертүне гамәлгә ашыра;

- проект эшчәнлеге өлкәсендә һөнәри компетентлыкны үстерү эшчәнлеген координацияли;

- проект эшчәнлегендә катнашучыларга карата квалификация таләпләрен бәяләүдә катнаша;

- проект эшчәнлегендә катнашучыларны укыта.

<u>Штаб (проект офисы) әгъзалары:</u>

- штаб (проект офисы) утырышларында һәм карала торган мәсьәләләр турында фикер алышуда катнашалар;

- штаб (проект офисы) утырышларында докладлар белән чыгыш ясыйлар;

- тикшерелә торган мәсьәләләр буенча штаб (проект офисы) каравына документлар һәм материаллар тәкъдим итәләр;

- штабның (проект офисы) чираттагы утырышында тәкъдимнәр кертәләр;

- көн тәртибенә фикер алышуга мәсьәләләр кертү турында тәкъдимнәр кертәләр;

- штаб (проект офисы) карарларын әзерләүдә һәм кабул итүдә катнашалар.

Проект офисы утырышын үткәрү турында карар проект офисы җитәкчесе яки проект офисы әгъзаларының берсе (штаб җитәкчесе күрсәтмәсе буенча) тарафыннан кабул ителә.

Штаб (проект офисы) утырышлары кирәк саен уздырыла.

Штаб (проект офисы) карарлары утырышта катнашучы штаб (проект офисы) әгъзаларының гомуми санынннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда, штаб (проект офисы) җитәкчесенең тавышы

хәлиткеч булып тора.

Штаб (проект офисы) утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул штаб (проект офисы) җитәкчесе тарафыннан имзалана.

Штаб (проект офисы) карарлары илкүләм проектларны гамәлгә ашыру кысаларында үтәү өчен мәҗбүри.